УДК 398.1

*И.К. Фазлетдинов*

# БАШКОРТСТАН ТАТАРЛАРЫНЫҢ АВЫЛ ТАРИХЛАРЫН ТАСВИРЛАГАН РИВАЯТЬЛӘРДӘ МИФОЛОГИК МОТИВЛАР

Статья посвящена исследованию тотемистических и анимистических мотивов в преданиях об историях сел и деревень татар Башкортостана, их взаимосвязи с историческими фактами. В ней отдельно выделяются и анализируются мотивы, связанные с культом животного в сознании предков современных татар; исследуются различные интерпретации мотива «божественного предзнаменования» и «строительной жертвы» в преданиях указанного типа. Автор приходит к выводу о том, что данные произведения являются синтезом тотемистических, анимистических и антропоморфических воззрений наших предков с реальной историей народа.

**Ключевые слова:** предание, мифология, анимизм, тотемизм, антропоморфизм, мотив, трансформация, культ, предзнаменование.

The article is devoted to the study of totemic and animistic motifs in the legends about the stories of villages of the Tatars of Bashkortostan, their relationship with historical facts. It separately identifies and analyzes the motives associated with the cult of the animal in the minds of the ancestors of modern Tatars; examines various interpretations of the motive of «divine omen» and «building sacrifice» in the legends of this type. The author comes to the conclusion that these works are a synthesis of totemic, animistic and anthropomorphic views of our ancestors with the real history of the people.

**Keywords:** legend, mythology, animism, totemism, anthropomorphism, motive, transformation, cult, omen.

Авыл атамаларының барлыкка килүе филология фәнендә берничә яссылыкта өйрәнелә. Тел галимнәре, мәсәлән, аңа телдәге номинация күренешен өйрәнгәндә кагылалар һәм аларны «икенчел номинация»нең бер төре буларак тикшерәләр. Аның төп мәгънәсе телдә инде күптәннән яшәп килгән сүзләрнең кулланылыш функциясен үзгәртү, шул рәвештә, аларның яңа эчтәлек алуына һәм яңа вазифада файдаланыла башлавына кайтып кала [Телия, с. 129]. Шулай итеп, атамада чагылыш тапкан сүзләрнең семантикасы үзгәрә, чынбарлыкның кеше аңында художестволы чагылыш табуы нәтиҗәсендә, алар туры мәгънәләре белән түгел, ә икенче, ассоциатив мәгънәдә кабул ителә башлый [Телия, с. 130]. Бу процессның аңда ни рәвешле баруын авыл тарихларын тасвирлаган риваятьләрдән дә күрергә мөмкин.

Кызганычка каршы, географик атамаларның, авыл исемнәренең барлыкка килү процессын махсус тикшерү эше белән соңгы елларга кадәр, нигездә, телче галимнәр генә шөгыльләнде. Аларның

хезмәтләрендә төп игътибар гыйльми этимологиягә бирелә. Атаманы халыкның үз күзлегеннән, үз тормыш тәҗрибәсенә таянып аңлату рәвешен анализлау исә икенче планга күчте. Рус риваятьләре материалына нигезләнеп, әлеге мәсьәләне махсус тикшерү эшен Н.А. Криничная башлап җибәрде. Географик атаманың барлыкка килү мотивын ул «төбәккә килеп урнашу һәм аны үзләштерү» циклына караган риваятьләр составында карый һәм аны «топонимик мотив» дип атап, еш кына риваять сюжетын хасил итеп килүен билгели [Криничная, с. 70]. Галимә әлеге мотивның өч төп версиядә гәүдәләнеш табуын ассызыклый:

1) Атама төбәккә беренче булып килеп утырган кешенең исеменә, я булмаса, кушаматына нигезләнеп аңлатыла [Криничная, с. 70];

2) Атама авыл урнашкан урынның борынгы исемен үзенә күчерә [Криничная, с. 71];

3) Атама төбәккә беренче булып утырган кешенең, я булмаса аборигенның милли үзенчәлекләренә бәйле рәвештә барлыкка килә [Криничная, с. 73–74].

Галимә фольклордагы топонимик мотивның «тарихи, этнографик, географик фактларга һәм лингвистик законнарга, гадәттә, бөтенләй буйсынмавын» ассызыклап үтә һәм шул ук вакытта, нәкъ шушы сыйфатның риваять сюжеты барлыкка килүгә һәм аның үстерелүенә аерым мөмкинлекләр ачуын билгели [Криничная, с. 77]. Без исә Башкортстан татарларының авыл тарихларын тасвирлаучы риваятьләрендәге авыл атамасының барлыкка килү мотивы әлеге өч версиягә генә сыешып бетми, дигән фикердә торабыз.

Билгеле булуынча, бүгенге көндә күпчелек халкын татарлар тәшкил иткән авыллар, нигездә, Башкортстанның төньяк-көнбатышында урнашкан. Аларның барлыкка килүен тасвирлаган риваятьләрнең күпчелегендә авыл исеменең килеп чыгышы да аңлатыла. С.М. Гыйлаҗетдинов билгеләвенчә, бу – «топонимик риваятьләргә хас күренеш» [Татар…, 1987, б. 13].

Кулыбызда булган риваять материалыннан күренүенчә, Башкортстандагы күп кенә татар авылларының атамалары халкыбызның борынгы мифологик күзаллаулары, атап әйткәндә, тотемистик һәм анимистик карашларына нигезләнеп барлыкка киләләр.

Мондый риваятьләрдән ата-бабаларыбызның тере табигатьне изгеләштереп каравын да, тормыштагы һәр күренештән яшерен мәгънә эзләвен дә, үзенә теләктәшлек, ярдәм сорап, илаһи көчләргә табынуын да күрергә мөмкин. Табигатьтәге һәр күренешне борынгы кеше үзенчә интерпретацияләгән, аңа үзенчә бәя биргән, реаль чынбарлык белән бәйләргә тырышкан. Шуңа да авыл атамаларын мифологик карашларга нигезләнеп аңлаткан риваятьләрдә файдаланылган мотивлар үзләренең күптөрлелеге белән аерылып тора. Шундыйларның берсе – борынгы хайваннар культына, аларны изгеләштерүгә корылган. Әлеге культка караган образлар пантеонында ат образы аерым урын тота. Фольклорчы-галим Фатих Урманче билгеләвенчә, «ат

башта тотемистик карашлар формалашуда җитди роль уйнаса, акрынлап мәҗүси алла дәрәҗәсенә күтәрелә. Төрки-монгол һәм төрки-татар халыклары мифологиясендә һәм фольклорында күп гасырларга сузылган әлеге процессның төрле этаплары чагылыш таба» [Урманче, 2008, б. 124].

Моның ачык чагылышын төрки халыкларның риваятьләреннән, шул исәптән, авыл тарихларыннан да күрергә мөмкин. Фольклорчы-галим Ф.А. Нәдершина фикеренчә, «яңа җирләргә килеп нигезләнү» мотивы күпчелек риваятьләрдә традицион алымга таяна: фәлән-фәлән кешенең угланнары (алар, гадәттә, ике, өч, биш агай-эне итеп алына) югалган йорт хайваннарын эзләп килеп, шулар туктаган уңдырышлы җирдә нигез корып, ыру җәеп, яшәп китә» [Нәҙершина, б. 130].

Бу алым Башкортстан татарлары риваятьләре өчен дә традицион. Мәсәлән, Туймазы районы Ярмөхәммәт авылы тарихын тасвирлаган риваятьтә [Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш…, б. 37–38] «Әй буенда яшәүче берәүнең ат өере» югалуы, шуларны «эзләп, ике кеше безнең якларга килеп» чыгуы һәм биредә «малкайларның үләнгә мул, бай урында ашап» йөрүен күрүе бәян ителә. «Бу урын кешеләргә бик охшый» һәм шуңа күрә «Ярмөхәммәт исемле кеше шушында күченеп» килеп, яңа авылга нигез сала һәм аңа үз исемен бирә.

Кыйгы районы Үрге Кыйгы авылы турындагы риваятьнең бер варианты да [Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк…, б. 40] охшаш сюжетка корылган. Биредә Кыйгыр исемле бер «ярлы егет»нең аты югалу, «аптырагач», аның «ат көтүчесе булып» урнашуы, ләкин «көтүгә бүреләр һөҗүм» ясап, «берничә атны имгәтеп» ташлаулары сурәтләнә. Кыйгыр җәзадан качып, «безнең якларга килеп чыга» һәм шунда «урманда йөргәндә ат көтүен күреп кала». Шулчак, «бер бия аның янына килеп баса. Бу – Кыйгырның аты була. Егет шушында өй сала, гаилә корып җибәрә». Шулай итеп, югарыда телгә алынган ике риваятьтә дә «кешеләрнең үз мал-туарлары котлы урын табып бирә» [Нәҙершина, б. 131]. Бу исә борынгыларның атны изгеләштереп карауларының ачык дәлиле булып хезмәт итә.

Күчеп утыручылар кайчандыр ташлап киткән чирле мал-туарның яңа урында кыш чыгып, хуҗаларын каршылавы һәм, шуңа бәйле рәвештә, авылга әлеге җирдә нигез салынып, исем табылу мотивына корылган риваятьләрдә дә халкыбызның борынгы ат культы үзенчәлекле чагылышын таба. Мәсәлән, Стәрлебаш районы Бүзат авылы тарихын тасвирлаган үрнәктә [Фазлетдинов. Стәрлебаш…, б. 423] «өч Пенза татары»ның яңа урыннарны килеп караулары, охшатулары, ләкин, кайтыр юлга чыккач, аларның бер атлары кинәт авырып» китүе сурәтләнә һәм «юлчылар аны бер чишмә янында калдырып китәргә мәҗбүр» булулары хакында хәбәр ителә. «Бер ел тирәсе вакыт үткәч, 7 гаилә бу якларга күчеп киләләр һәм чишмә янындагы аланга төпләнәләр. Бер көнне суга барган хатын-кызлар чишмә янында бер ат очраталар... Ул үткән килгәндә калдырып киткән чирле ат булып чыга. Бу ат – акбүз ат була. Аның савыгуына һәм исән-сау

кышлавына куанган халык авылларына Акбүзат дип исем кушарга булалар». Әлеге риваятьтә борынгы бабаларыбызның мифологик карашлары ачык күзаллана.

Ф.А. Нәдершина язуынча, «ак, бүз (күк) атлар төрле халыкларның мифологиясендә кешеләргә бәхет китерүче, изгелекле җан ияләре сыйфатында чагылыш тапкан» [Нәҙершина, б. 85]. Бу фикерне башка тикшеренүчеләр дә куәтли. Мәсәлән, Галимҗан Гыйльманов акбүзатны Кояш символы итеп карый. «Шуңа күрә, борынгы ышану буенча, акбүз атка атлана алган, аны үзенә буйсындыра алган кеше изге максатына ирешә – җир астына да төшә, утлы таулар аша да чыгып, бер төн эчендә дөньяның читенә дә барып җитә ала» [Татар..., 1996, б. 55]. Шулай итеп, белгеч фикеренчә, «Акбүз атлар яктылыкны, Көнне, Кояшны гәүдәләндергәннәр» [Татар..., 1996, б. 55].

Югарыда телгә алынган риваятьтә, без әлеге илаһи көчкә ия булган мифологик персонаж – Акбүзатның халыкның иҗтимагый аңы үсеше нәтиҗәсендә трансформация кичереп, гадәти җир тормышына якынаюын күрәбез. Биредә аның югарыда санап үтелгән илаһи сыйфатлары чагылыш тапмый. Бу исә риваятьнең борынгы мифлардан, экиятләрдән соңрак иҗат ителүен дәлилли. Ләкин, шул ук вакытта, борынгы мифологик карашларның әлеге риваятькә тәэсире дә ачык тоемлана. Пенза татарлары тарафыннан калдырып кителгән чирле атның савыгып, бер елдан үзләрен шушы җирдә каршы алуы ниндидер гайре табигый, сәбәбенә төшенергә гади акыл гына җитмәслек вакыйга итеп карала һәм әлеге «могҗиза» атның, борынгылар карашынча, илаһи көчкә ия акбүз ат булуы белән аңлатыла. Акбүзатның кешеләрне яңа урында каршы алуы, шулай ук, нигез корасы җирләрнең уңдырышлы, үлән-суга бай, яшәр өчен уңайлы, котлы икәнлеген күрсәтүче илаһи билге сыйфатында да чыгыш ясый. Шуңа да кешеләр авылны Акбүзат дип атап, киләчәктә үзләрен бәла-казадан сакларга, яңа урында үзләренә бәхетле тормыш тәэмин итәргә омтылалар. Риваятьтән күренүенчә, борынгы мифологик карашлар халыкның бүгенге реаль тормыш ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен, ягъни практик максатларга хезмәт итәләр.

Шул ук вакытта әлеге үрнәк авылның борынгылыгы, аның халык аңында мифологик күзаллаулар хакимлек иткән чорларда ук нигезләнүе турында фаразларга мөмкинлек бирә. Рус фольклорчысы Н.А. Криничная билгеләвенчә, атны изгеләштерү кешелек җәмгыятенең иң борынгы чорларында ук барлыкка килеп, ул «явыз көчләрдән саклаучы, мәҗүси тәңреләрнең кодрәтен кешеләргә җиткерүче илаһи зат» буларак, авыл тарихларын тасвирлаучы риваятьләр составына килеп керә [Криничная, б. 50]. Күренекле галимебез Ф.И. Урманчеев Бүзат, яки Акбүзатның борынгы төрки-монгол эпосларында «Күктән төшкән илаһи зат, батырның җиңелмәс яклаучысы» сыйфатында сурәтләнүен күрсәтә [Урманчеев, с. 309].

Димәк, яңа урында беренче булып очраган ат – инде гади йорт хайваны гына түгел. Борынгы халык аны шушы җирләрнең хуҗасы,

иясе итеп карый, тәңреләрнең ихтыярын кешеләргә җиткерүче – арадашчы дип саный һәм, авылга аның исемен биреп, илаһи көчләргә хөрмәт-ихтирамын күрсәтергә тырыша, киләчәктә кешеләргә мәрхәмәтле булуын, зыян китермәвен үтенә. Шулай итеп, әлеге җанвар үз җирләренә күчеп утырган кешеләрнең киләчәге белән идарә итәргә сәләтле изге җан – тотем дәрәҗәсенә күтәрелә. Югарыда китерелгән риваятьтә нәкъ шушы зооморфик һәм антропоморфик карашлар чагылыш таба.

Димәк, Бүзат авылы тарихында ат культы ике яктан ачыла дигән нәтиҗәгә килергә мөмкин. Аның беренчесе татар халкының борынгы мифологик карашларын үзендә чагылдырса, икенчесе милләттәшләребезнең реаль тормыш ихтыяҗларына бәйле рәвештә барлыкка килә. Еллар узу белән, риваятьтәге илаһи акбүзат үзенең күп кенә мифологик атрибутларын җуеп, кешенең аерылгысыз юлдашы, терәге – гадәти җир атына әверелә.

Башкортстан татарларының авыл тарихларын тасвирлаган риваятьләрендә аттан башка йорт хайваннарын изгеләштерү функциясен дә күрергә мөмкин. Мәсәлән, Зилаер районы Чуенчы-Чупан авылы турындагы риваятьтә [Башкортстан татарлары фольклоры. Риваятьләр…, б. 52–54] тәкә культын ачык тоемларга мөмкин. Биредә «якын-тирә авылларда яшәүче башкортлар авылыбызны Каратәкә дип тә» атаулары турында хәбәр ителә һәм моның сәбәпләре аңлатыла: «Авыл корырга тәгаенләнгән җирдә Чупан байның җәйләве булган. Көз җитеп, малларны утарга ябып куйганда, ни сәбәптәндер, бер тәкә бүленеп калган. Кибән төбендә кыш чыгып, яз көне хуҗаларын каршы алган. Шуннан авылга Каратәкә исеме ябышып калган».

Риваятьтән күренүенчә, «Чуенчы-Чупан – Зилаер районында бердәнбер татар авылы. Ул 1901 елда барлыкка килгән». Каратәкә атамасы исә бу җирләрнең борынгы хуҗалары – башкортлар арасында бик күптәннән, әле Дәүләкән районы Чуенчы авылыннан татарлар килеп, җир сатып алып, шушы урында төпләнгәнгә кадәр үк яшәгән. Шуңа да аның тамырлары мифология белән бәйле традицион мотив – йорт хайванының яңа урында кыш чыгып, хуҗаларын каршылавы һәм, шуңа бәйле рәвештә, авылга әлеге урында нигез салынып, исем табылуына килеп тоташа. Биредә тәкә кешеләргә төпләнер урын табып бирүче изге хайван дәрәҗәсенә күтәрелә һәм атаманың барлыкка килүенә сәбәпче була. Туймазы районы Карамалы-Гобәй авылы тарихының икенче вариантында [Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш…, б. 32] үгез культының тәэсире тоемлана. Ул шулай ук традицион мотивка – югалган йорт хайванының хуҗаларына яшәр урын табып бирүенә корылган. Ләкин биредә кешеләргә яшәр өчен урынны тере түгел, ә үле мал-туар күрсәтә. Риваятьтә, «Кәлшәле авылыннан» югалган «бер кара үгез»нең «елга буеннан» тиресе генә табып алынуы, шуңа бәйле рәвештә, халыкның елгага Карамалы исемен бирүе («чөнки тире кара төстә була»), аның янындагы «авыл да Карамалы-Гобәй дип атала» башлавы тасвирлана. Шулай итеп, әлеге

үрнәкне халыкның борынгы мифологик карашлары таркала башлаган чорда иҗат ителгәндер, дип уйларга кирәк, чөнки биредә югалган мал-туарның хуҗа кешене яңа җирдә «могҗизалы» каршылавы кебек вакыйгалар урын алмый. Авыл нигезләнәсе урында үгезнең тиресе генә табылуы да традицион мотивның трансформация кичерүен – илаһи сыйфатларын югалтып, реаль тормышка якынаюын дәлилли.

Башкортстан татарларының авыл тарихларын тасвирлаган риваятьләрендә яңа урнашкан җиргә тере мал-туар корбан итү мотивы аерым игътибарга лаек. Аның нигезендә шулай ук хайваннар культы ята, дип исәпләргә кирәк.

Яңа нигезгә тере корбан китерү йоласы тамырлары белән ерак тарихка килеп тоташа. Н.А. Криничная фикеренчә, «борынгы заманнарда йорт салынасы урынга беренче булып аяк баскан кеше корбанга китерелгән. Ул – илаһи көчләр тарафыннан сайланган изге шәхес дип ышанылган һәм һәртөрле очраклылык биредә инкяр ителгән. Гадәттә, борынгы җәмгыятьтә корбанга гыйффәтле яшь кыз, сөекле ана, яраткан хатын һәм нигез салучы өчен башка якын кеше китерелгән» [Криничная, с. 57]. Борынгылар уйлавынча, «төзеләсе йортка шушы йоладан соң җан кергән, ул корбанга китерелгән кешенең холыкфигыль сыйфатларын үзенә алган» [Криничная, с. 59].

С.М. Гыйлаҗетдинов әлеге мотивның Казан шәһәренә нигез салынуны тасвирлаган «Елан тавы» [Татар…, 1987, б. 49–50] һәм «Умартачы кызы» [Татар…, 1987, б. 50–51] риваятьләрендә чагылыш табуын билгеләп үтә. Аларда «кала төзеләсе урын еланнардан азат ителгәч, хан бу җиргә аяк баскан иң беренче кешене җир астына күмәргә боера. Ләкин бу кеше хан улы икәнлеген күргәч, төзүчеләр аның урынына этне күмәләр. Изге йола бозылганлыктан, риваятьләр Казанның киләчәктә җимереләчәген фараз итәләр» [Гилязутдинов, с. 24]. Димәк, йорт саласы урынга корбан китерү борынгы җәмгыятьтә мәҗбүри йола булып исәпләнгән һәм аны бозу төрле бәлаказаларга илтә, дип ышанылган. Э. Тайлор раславынча, әлеге йола «борынгы вакытларда чыннан да булган гына түгел, ә озак вакыт Европа тарихында да яшәп килгән» [Тайлор, с. 61].

Кешелекнең аң ягыннан үсеше нигезгә тере бала корбан итү йоласына зур үзгәрешләр кертә. Н.А. Криничная язуынча, борынгы ышануларны югалту нәтиҗәсендә, ул изге һәм мәҗбүри гамәлдән мәгънәсез кеше үтерүгә әверелә. Йоланың трансформация кичерүе, корбан ителәсе кешенең нинди дә булса йорт хайваны: әтәч, тәкә, ат белән алыштырылуына китерә. Ләкин корбан булып, бары тик кешене алыштыра алырлык изге мал-туар гына хезмәт итә ала. Һәм биредә яңа нигезгә кеше корбан итү йоласының трансформациясен генә түгел, ә халыкның борынгы тотемистик ышануларын да күрергә мөмкин [Криничная, с. 58].

Әлеге мотив Илеш районының Бишкурай авылы тарихын тасвирлаган риваятьтә [Башкортстан татарлары фольклоры. Үзәк…, б. 39] үз чагылышын таба. Биредә «кураз» сүзенең «фарсы теленнән»

кергәнлеге һәм «мәгънәсе әтәч дигәнгә» туры килүе турында хәбәр ителә. Яңа урынга күчеп килгән биш гаилә басуга үзләре белән «берәр әтәч алып» чыга һәм «җир башында» аларны «суеп йолкалар». Шуннан соң гына «моңа тиклем кеше кулы тимәгән җирнең чирәмен күтәрәләр. Шул биш әтәч исеме белән Бөет язы дигән су буенда авыл нигезләнә. Беренче йортны салганда да биш әтәч сую йоласы башкарыла. Шуңа да авылны Бишкураз дип атап йөртә башлыйлар».

Күренүенчә, риваятьтә тасвирланган йоланың төп максаты – «җир ияләренең күңелен күрү» [Тайлор, с. 61]. Корбан китереләсе мал сыйфатында кешеләрнең әтәчне сайлавы да очраклы түгел. Галимҗан Гыйльманов фикеренчә, «әтәч – дөнья халыклары мифологиясендә Кояшны символлаштыручы җан иясе. Аларның асыл мифик мәгънәләре бер үк – вакыт санау.., ул Кояш кебек үк сакчыллык, иминлек символы булып та тора» [Татар..., 1996, б. 49]. Димәк, Бишкурай авылы турындагы риваятьтә борынгылар яңа урында чәчүлек ясар, йорт салыр алдыннан биш әтәчне корбан китереп, Җирдән, Кояштан муллык, иминлек, әлеге җирдә киләчәк тормышларының бәхетле булуын сораганнар. Авылны корбанга китерелгән кош-корт исеме белән Бишкураз дип атау да нәкъ шушы максатлардан чыгып башкарылган. Биредә әтәчне изгеләштереп, аны илаһи сыйфатларга ия итеп карау ачык тоемлана.

Яңа нигезгә тере мал-туар корбан итү мотивы Кушнаренко районы Каратәкә авылы тарихын тасвирлаган риваятьтә дә [Башкортстан татарлары фольклоры. Риваятьләр…, б. 71] чагылыш таба. Монда әлеге урынга беренче булып килеп төпләнгән мулланың «берсе – ак, ә икенчесе – кара» төстәге ике тәкәсе булуы, «бер бәйрәмдә» ак тәкәнең корбанга чалынуы турында хәбәр ителә. «Мулла нигез салган авылга башка күчеп килүчеләр... мулланың тәкәсен күреп, үзара килешеп, авылга Каратәкә исемен биргәннәр»,– дип әйтелә риваятьтә.

Күренүенчә, әлеге үрнәктә корбанның кемгә атап, ни рәвешле китерелгәне тасвирланмый, ягъни бу – йоланың мәгънәви нигезе, сәбәпләре халык хәтереннән җуелып баруына бер дәлил булып тора. Ләкин, тикшеренүчеләр раславынча, борынгы төркиләрдә ак тәкә – «Җир өстенә яктылык бирә торган Көн Кояшын», кара тәкә – «Җир асты Кояшын» символлаштырган [Татар..., 1996, б. 44]. Галимҗан Гыйльманов үз хезмәтендә бу фикерне дәлилләп, этнографиягә мөрәҗәгать итә һәм Түбән Кама керәшеннәрендә әлегә кадәр сакланган Учук йоласын китерә. «Аны, чын мәгънәсендә, Кояштәңрегә табыну йоласы дип атарга мөмкиндер,– ди ул. – Бу көнне авылда (яки йортта) ак тәкә суялар. Итләр пешеп чыккач, кояшка таба карап, келәүләр әйтә башлыйлар... Һәркем үзенчә теләгән: җылы кирәк булганда – җылылык, кояш нуры теләгәннәр; яңгыр булмаганда – яңгыр; кысрыклык, корылык булганда – икмәк; балалары булмаганнар бала теләгәннәр. Кояш тәңресе мәрхәмәтле, җирдәге бөтен иминлек, бәхет аның кулында, дип уйлаганнар» [Татар..., 1996, б. 44].

Югарыда китерелгән риваятьтә дә шушы ук ритуал – Кояшка табыну чагыла. Мулла ак тәкәне корбанга китереп, Кояштан үзенә яңа җирдә имин, бәхетле тормыш сораган, дип фараз итәргә мөмкин. Ә соңрак күчеп килүчеләр, авыл атамасында Кара тәкә исемен мәңгеләштереп, җир асты көчләреннән үзләренә мәрхәмәтле булуларын, зыян китермәүләрен үтенгән. Шулай итеп, беренче карашка, гадәти тормыш вакыйгасын тасвирлауга корылган риваять, чынлыкта, халкыбызның борынгы мифологик карашларын, йолаларын чагылдыра.

Башкортстан татарларының авыл тарихларын тасвирлаган риваятьләрендә күчеп утыручыларга яшәр өчен җирне теге яки бу хайван, яисә кош бүләк итү мотивы да зур урын тота. Аның нигезендә шулай ук борынгы тотемистик карашлар, тере табигать культы ята, дип исәпләргә тулы нигез бар, һәм бу еш кына авыл атамаларында ук чагылыш таба.

Мәсәлән, Шаран районының Күгәрчен Бүләк авылы турындагы риваятьтә [Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш…, б. 39–40] күчеп килүчеләргә бу җирләрне күгәрченнәр «бүләк итүе» тасвирлана. «Яланның уртасында үсеп утырган ялгыз имән башына күгәрченнәр оялаган була. Алар юлчыларны күрү белән, күккә күтәрелеп, гөрли башлыйлар. «Түрдән узыгыз! Китмәгез! Бу бездән сезгә бүләк! – дигән төсле, кешеләрнең өстеннән әйләнеп очалар.

Юлчылар: «Бу безгә күгәрченнәрдән бүләктер, алар безне җибәрергә теләмиләр», – дип уйлап, монда төпләнеп калырга уйлыйлар. Әбием сөйләве буенча, шулай итеп, Күгәрчен Бүләк исемле авыл барлыкка килә», – дип хәбәр ителә риваятьтә. Биредә күгәрчен культы ачык тоемлана. Халык бу кошларны илаһи көчкә ия, изге зат итеп санап, күгәрченнәрнең баш очына күтәрелеп, гөрли-гөрли очуларында да символик бер билге, мәгънә таба. «Димәк, әлеге җирләрдә төпләнсәк, тормыш имин, яхшы булачак. Югары көчләр күгәрченнәр аша шуны хәбәр итәләр», – дип уйлый борынгы кеше. Шулай итеп, ул үзенә хас уйлау, сөйләшү, бүләк итү кебек сыйфатларны әлеге кошларга да күчерә. Ягъни биредә борынгы мифологиягә хас җанлы һәм җансыз табигатьне кешеләштерү – антропоморфизм чагылыш таба. Халык күгәрченнәрне «Күк һәм Җир арасында илче-хәбәрче вазифасын башкаручылар» [Татар..., 1996, б. 189] итеп күрә һәм моны авыл атамасында да чагылдыра.

Шуны да әйтик, күгәрчен культы татар халкының туй, йола җырларында, күп әкият-дастаннарында ачык тоемлана. «Аларның һәммәсендә дә күгәрчен мәрхәмәтлелек, тынычлык һәм, нигездә, саф мәхәббәт символы булып кала» [Урманче, 2009, б. 174].

Яңавыл районының Айбүләк авылы тарихын тасвирлаган риваятьтә дә [Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк…, б. 55–56] тотемистик карашлар, аю культы чагылыш таба. Ләкин алар биредә тирәнгәрәк яшерелгән. Беренче карашка, риваять гадәти көнкүреш вакыйгасына корылган кебек. Биредә «урманны кисеп, авыл төзи башлагач, барлык аюлар да качышып» бетүе, «кайберләрен исә»

халыкның «аулап» үтерүе турында хәбәр ителә. Имеш, шуннан соң бу урын «Аю бүләк итеп калдырган авыл» дип атала башлый. Шулай итеп, атаманың килеп чыгышы халыкның образлы фикерләвен генә чагылдыра, дип тә уйларга мөмкин. Ләкин «төрле континентларда яшәүче халыкларның материалын гомум байкап чыгу һәм өйрәнү нигезендә аюга бәйле карашларның бик борынгы һәм күп яклы булганлыгы ачыкланды. Җыеп кына әйткәндә, дөнья мифологиясендә чагылган бу образның сыны, «кыяфәте» һәм роле шушы рәвешле күзаллана: аю – илаһи җан (божество); кешеләргә файда китерүче изгелекле культур герой (мәсәлән Обь угорлары, ненецлар аюны үзләренә ут алып килүче изге җанвар дип исәпли); теге яки бу традицияне башлап җибәрүче; нәсел җебен таратучы тотем, җир асты дөньясының хуҗасы; изге корбан хайваны; аю кыяфәтендәге кеше, шаман ярдәмчесе һ.б.» [Нәҗершина, б. 38]. Югарыда сөйләнгән риваятьтә дә аюның «кешеләргә файда китерүче изгелекле герой» булганлыгы күзгә ташлана. Аюларның кешеләргә яшәр җир бүләк итүе турындагы этиологик мотив үзе үк әлеге затның антропоморфик сыйфатларга ия икәнлеген күрсәтә һәм бу авыл халкында гасырлар дәвамында аю культы яшәп килгәнлеген дәлилли. Халыкның аң ягыннан үсеше нәтиҗәсендә, борынгы бабаларыбызның мифологик карашларын – аюны җир иясе, изге хайван итеп санауны чагылдырган мотив бары тик эстетик вазифа үти башлый. Әлеге риваятьтә мифологиянең «күзгә бәреп» тормавы да шуның белән аңлатыла, чөнки ул үзенең борынгы рәвешеннән нык үзгәргән, халык аңында күп кенә детальләрен җуйган булуы мөмкин.

Башкортстан татарларының авыл тарихларын тасвирлаган риваятьләрендә авылны яңа җирдә, ау вакытында иң беренче булып очраган җәнлек исеме белән атау мотивы да чагылыш таба. Аның нигезендә шулай ук халкыбызның борынгы тотемистик ышанулары ята. Мәсәлән, Краснокама районының Иске Кабан авылы турындагы үрнәктә [Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк…, б. 37] «кешеләр, шушы урынга килеп утыргач та, аңа исем эзли» башлаулары һәм «ауга чыкканда нинди җәнлек очрый, шуның исемен бирергә» карар кылулары турында хәбәр ителә. Икенче көнне ауга чыгуга, аларга кабан дуңгызы очрый... Авылга Кабан дигән исем бирәләр»,– дип аңлатыла риваятьтә атаманың килеп чыгышы.

Туймазы районының Чокадытамак авылы турындагы риваять тә [Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш…, б. 37] шушы ук мотивка корылган. Биредә өч егетнең «чишмә янында тукталып хәл җыйганда», «өч кыр казы атып» алулары, шуннан «озак та уйлап тормыйча, биредә яшәргә төпләнергә» карар итүләре һәм авылны «беренче табышлары исеме белән – Өч казы дип» атаулары тасвирлана.

Яңа урында беренче булып очраган җанвар – гади җәнлек түгел. Борынгы халык аны шушы җирләрнең хуҗасы, иясе итеп карый һәм авылга аның исемен биреп, үзенең шушы җанварга булган хөрмәт-ихтирамын күрсәтергә тырыша, киләчәктә кешеләргә мәрхәмәтле

булуын, зыян китермәвен үтенә. Шулай итеп, әлеге җанвар үз җирләренә күчеп утырган кешеләрнең киләчәге белән идарә итәргә сәләтле изге җан – тотем дәрәҗәсенә күтәрелә. Югарыда китерелгән риваятьләрдә нәкъ шушы антропоморфик карашлар чагылыш таба. Алар борынгы халыкның җанлы табигать белән тыгыз бәйләнештә торганлыгын, аны кешедә булган барлык сыйфатларга да ия илаһи зат итеп карауларын исбатлыйлар. Авыл атамаларында тере йорт хайваны, кыргый җәнлек исемнәре гамәли максатлардан чыгып, халыкның яңа җирдә бәхетле тормышын тәэмин итү өчен файдаланыла. Аң ягыннан үсеш кичереп, мифология кеше тормышындагы хәлиткеч ролен югалткач кына, хайваннар дөньясыннан алынган тотемнар эстетик вазифа үти башлый. Шулай итеп, бары тик «инануга нигезләнгән мотивларның уйдырма икәненә әкренләп төшенү аркасында, мифологик сюжетлар халык аңында әкияткә яки легендага, ә тотемнар художестволы образларга күтәрелә» [Әхмәтйәнов, б. 61]. Каралган типтагы риваятьләрнең барлыкка килү процессын әнә шулай күзалларга кирәк.

Башкортстан татарларының авыл тарихларын тасвирлаган риваятьләре арасында илаһи билге («божественное предзнаменование») мотивына корылган үрнәкләр дә очрый. Аның мәгънәсе шунда: илаһи көчләр күчеп килүчеләргә төпләнер өчен урынны магик билге аша үзләре күрсәтәләр һәм бу атамада да чагылыш таба. Югары көчләр бу билгене төрлечә бирергә мөмкин. Мәсәлән, Чишмә районы Яңавыл (борынгы исеме Күчәрсынды) авылы турындагы риваятьтә [Башкортстан татарлары фольклоры. Риваятьләр…, б. 97] мондый билге булып арба күчәре сыну вакыйгасы хезмәт итә. Шуны да әйтик, арба күчәре сыну – илаһи билге икәнлеге яшәргә яңа җир эзләп юлга чыгучылар өчен алдан ук мәгълүм була һәм, шул рәвешле, урын сайлау өчен мотивация баштан ук билгеләнә: «Чыгар алдыннан кабиләнең ир-атлары үзара килешеп куялар: «Менә без хәзер юлга чыгабыз. Кайда арбабызның күчәре сына, шунда тукталабыз», – диләр. Боларның арба күчәрләре нәкъ безнең авыл утырган урында ватыла». Күренүенчә, арба күчәре сыну биредә, чыннан да, югары көчләр тарафыннан җибәрелгән илаһи билге сыйфатында чыгыш ясый. Күчәрнең теләсә нинди урында сынмыйча, кешеләргә яшәр өчен уңайлы урында гына сафтан чыгуы да шуны раслый. «...Бер яктан елга агып ята, икенче якта – урман. Нигә шушында төпләнмәскә? Кабилә башлыгы Сәгыйть һәм ырудашлары шушында калырга карар итәләр. Авылга алар Күчәрсынды дигән исем бирәләр».

Шулай итеп, биредә илаһи билге кешеләрнең практик ихтыяҗлары белән тәңгәл килә. Ул бу урыннарда тормышның яхшы, җирнең уңдырышлы, табигатьнең яшәр өчен уңайлы булуы, явыз рухларның зыян сала алмаячаклары турында хәбәр итә. Күчеп килүчеләр, «өстән» билгеләнгән урынга төпләнеп, авылны шушы вакыйгага багышлап атап, илаһи көчләрнең яклавыннан, мәрхәмәтеннән файдаланырга өметләнәләр. Димәк, биредә дә халыкның борынгы ышанулары чагылыш таба.

Шушы ук мотив Татарстанның Буа районы Казма авылы тарихында да кабатлана [Татар…, 1987, б. 156–157]. Биредә «Татар Мәмәтхуҗасыннан»... «кая гына күчермәсеннәр, шунда утырам инде»,– дип, яңа җир эзләүче бер бабайның зиректән ясалган «арба күчәре»нең «казылмага төшеп» сынуы һәм шул урында әлеге исемдәге авыл хасил булуы турында хәбәр ителә. Алдагы үрнәктән аермалы буларак, биредә арба күчәре сыну турыдан-туры илаһи билге итеп каралмый, урын сайлауга мотивация дә алдан билгеләнми. Авылның шушы җирдә нигезләнүе дә, күчеп килүче бабайның ары барырга мөмкинлеге булмау белән (арба күчәре сынык), ягъни объектив ситуациядән чыгып аңлатыла. Бу, үз чиратында, әлеге риваятьнең Чишмә районы Күчәрсынды авылы турындагы үрнәктән соңрак, халыкның мифологик карашлары таркалган чорда иҗат ителгәнлеген күрсәтә. Шул ук вакытта биредә әлеге «илаһи билге» мотивының таралу географиясе дә зур булганлыгы ачык күзаллана.

Караидел районының Өч тиен авылы тарихын тасвирлаган риваятьтә [Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк…, б. 33] мондый билге булып, яңа урыннан тимер акча табылу вакыйгасы хезмәт итә. Ул авылга исем кушылуга да сәбәпче була. Акча тапкач, мосафир:

«– Күп җирләрдә булдым, озын гомер гиздем, тик бәхетне тапмадым, – ди.

– Бу өч тиен акча юкка гына булмас, Ходай бирде аны миңа, – ди.

– Бирәм дигән колына, чыгарып куяр юлына, шуннан да шәп җир булмас, – ди.

Йорт салып, кәләш алып җибәрә. Авыл исеме шуннан торып калган».

Шулай итеп, юлдан акча табылу вакыйгасы биредә күчеп утыручыга монда төпләнергә кушып, Ходай тарафыннан җибәрелгән әмер сыйфатында чыгыш ясый. Тикшеренүчеләр язуынча, «Урта гасырлар башында алтын һәм көмеш әле акча сыйфатында файдаланылмый – натураль алмашу өстенлек итә. Борынгы җәмгыятьтә алар товар алмашу чарасы, яисә байлык җыю чыганагы булудан бигрәк, мөһим билге функциясен үтиләр...» [Гуревич, с. 196]. Аларда шушы байлыкка ия булган кешенең бәхете һәм уңышы материальләшә дип исәпләнә. Шуңа да, күп кенә йола һәм гадәтләрдә йорт төзегәндә почмаклар астына алтын, көмеш, ә кайчак бакыр акча салып калдыру күренеше бар: акча өйдән бәхет һәм байлык китмәсен өчен салына [Криничная, с. 114–115]. Ягъни алда телгә алынган риваятьтә дә яңа җирдән акча табылу бу урынга нигез салган кешеләрнең киләчәктә тормышы имин, бәхетле булачагын хәбәр итүче символ сыйфатында чыгыш ясый.

Илеш районының Теләкәй авылы турындагы үрнәктә [Башкортстан татарлары фольклоры. Үзәк…, б. 51] мондый илаһи билге булып, яңа урында кешеләрнең теләкләре кабул булу вакыйгасы хезмәт итә. Бу теләкләр шулай ук халыкның игенчелек белән бәйле тормыш ихтыяҗларына нигезләнә. Биредә «Казан ягыннан килүче бер төркем

кеше»нең очраклы гына бер җирдә туктап, «иген чәчеп» каравы һәм «Ел яңгырлы килсен, иген уңсын», дип теләк теләгәч, табигать көчләренең аларны тыңлавы, көзен уңыш мул булуы турында хәбәр ителә. «Кешеләр сөенешеп: «Иген уңды, теләкләребез кабул булды, әйдәгез, монда төпләнеп кенә калабыз!» – дигәннәр. Шулай итеп, яңа авыл хасил булган. Аны Теләкәй дип атаганнар.

Күренүенчә, бу үрнәктә дә халыкның борынгы ышанулары чагылыш таба. Игеннең мул булуын ул үзенең теләкләренең нәтиҗәсе итеп карый, югары көчләр аның тавышын ишеткәннәр, дип исәпли һәм монда төпләнсәләр, алар кешеләрне үз ярдәмнәреннән ташламас, дип ышана. Ягъни иген уңуы биредә шулай ук илаһи билге итеп карала.

Борынгы җәмгыятьтә кеше үзен явыз рухлардан саклар өчен төрле магик эчтәлекле ритуаллардан файдаланган. Мәсәлән, яңа өйгә бичура ияләшмәсен өчен, күченер алдыннан мич чыгару [Насыйри, б. 52], балага явыз көчләр зыян салмасын өчен, аны балигълык яшенә җиткәнче алмаш исем – җанвар, кош-корт исеме белән атап йөртү [Дмитриев, с. 14] борынгы профилактик магия чаралары булып торалар. Авылга исем кушу шулай ук биредә яшәүчеләрне явыз рухлардан саклаучы магик ритуал булгандыр, дип фараз итәргә мөмкин. Кызганычка каршы, аның тәртибе, рәвеше турында мәгълүматлар безнең көннәргә кадәр килеп җитмәгән. Ләкин «яшәгән урыныңа озак исем кушмасаң, йортыңа бәла-каза килер» дигән борынгы ышану бүгенгә кадәр яши. Һәм ул риваятьләрдә дә чагылыш таба.

Моңа мисал итеп, Авыргазы районы Ишле авылы тарихының беренче вариантын [Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш…, б. 24] китерергә мөмкин. Риваятьтә «бу җирләргә Казан ягыннан өчдүрт гаилә күчеп» утыруы һәм «көннәрдән бер көнне бу кешеләрнең маллары үлә» башлавы тасвирлана. «Гаеп җирдәдер»,– дип, алар яңа урынга күченәләр, ләкин монда да шул ук хәл кабатлана. «Бер көнне авылга Куҗак исемле бер бабай» килеп, бу казаның сәбәбен аңлата:

– Сез монда ишәеп киткәнсез икән, бер бәләкәй авылга әйләнгәнсез. Тик авылыгызга һаман исем кушмагансыз. Сез аны Ишле дип атагыз, – ди. Халык уйлана һәм, бабай белән килешеп, авылга Ишле исеме бирә».

Күренүенчә, авылга исем бирү биредә халыкны төрле бәлаказалардан саклаучы изге йола итеп бәяләнә, ә кешеләргә әлеге акыллы киңәшне биргән Куҗак бабай үзе илаһи зат дәрәҗәсенә күтәрелә. Риваятькә таянып, авылга атама бирүнең борынгы җәмгыять өчен олы әһәмиятен ачык күзалларга мөмкин.

Шулай итеп, авылны тотем җанвар, изге корбан исеме белән атау, атамада югары көчләр тарафыннан җибәрелгән «илаһи билгене» мәңгеләштерү кебек мотивларның риваятьләрдә үзәк сюжет хасил итүе кешеләрнең нәкъ әнә шул илаһи көчләр ярдәмендә үз-үзләрен бәла-казалардан, явыз рухлардан араларга тырышуы белән аңлатыла. Атамада урын алган изге җанвар, илаһи билге явыз көчләрне бирегә якын җибәрмәскә, халыкның бәхетле тормышын тәэмин итәргә

тиеш була. Мондый риваятьләр халыкның иң борынгы карашларын чагылдыра. Алар реаль чынбарлык күренешләре белән халкыбызның мифологик карашларын, иҗади фантазиясен бергә берләштереп килә һәм фольклорның башка жанрлары белән тыгыз мөнәсәбәттә торып, кабатланмас синтез тудыра.

**Әдәбият**

*Әхмәтйәнов К.Ә.* Поэтик образлылыҡ. Икенсе китап. Өфө: Китап, 1994. 192 б.

Башкортстан татарлары фольклоры. Риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни мөхәррире Ә.М.Сөләйманов Уфа: Китап, 2018. 344 б.

Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш районнар / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни редакторы К.М. Миңнуллин. Казан: ТӘһСИ, 2021. 312 б.

Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк һәм төньяк-көнчыгыш районнар / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни редакторы К.М. Миңнуллин. Казан: ТӘһСИ, 2021. 296 б.

Башкортстан татарлары фольклоры. Үзәк һәм төньяк-көнбатыш районнар / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни редакторы К.М. Миңнуллин. Казан: ТӘһСИ, 2021. 304 б.

*Гилязутдинов С.М.* Татарские исторические предания и легенды и их художественные особенности: автореф. дис. ... канд. филол. наук / ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Казань, 2000. 32 с.

*Гуревич А.Я.* Категории средневековой культуры. М.: Искусство, 1972. 318 с.

*Дмитриев С.В.* Мотив подмены младенца в сказках, легендах, преданиях // Фольклор народов РСФСР: межвузовский научный сборник / отв. ред. Л.Г. Бараг. – Уфа: Издательство БашГУ, 1990. С. 12–18.

*Криничная Н.А.* Русская народная историческая проза: вопросы генезиса и структуры / ответ. ред. В.К. Соколова. Л.: Наука, 1987. 232 с.

Милли-мәдәни мирасыбыз: Башкортстан татарлары. Стәрлебаш. 1 нче кисәк / төзүче Н.Ш. Насыйбуллина; фәнни мөхәррир И.И. Ямалтдинов. 2 нче басма. Казан: ТӘһСИ, 2021. 440 б. (Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән).

*Насыйри Каюм.* Сайланма әсәрләр: 2 томда. 1 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. 340 б.

*Нәҙершина Ф.А.* Халыҡ хәтере: монография / яуаплы редакторы Нур Зарипов. Өфө: Башҡортостан китап нәшриәте, 1986. 189 б.

*Тайлор Э.Б.* Первобытная культура / перевод с английского Д.А. Коропчевского, предисловие и примечания профессора А.И. Першица. М.: Государственное издательство политической литературы, 1989. 576 с.

Татар мифлары: ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, им-томнар, сынамышлар, йолалар. Беренче китап / Галимҗан Гыйльманов хикәяләвендә. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. 388 б.

Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар / томны төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы С.М. Гыйләҗетдинов; фәнни редакторы Х.Ш. Мәхмүтов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 368 б.

*Телия В.Н.* Вторичная номинация и ее виды // Языковая номинация: виды наименований / отв. ред. Б.А. Серебренников, А.А. Уфимцева. М.: Наука, 1977. С. 129–221.

*Урманче Ф.И.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: I т. (А – Г). Казан: Мәгариф, 2008. 303 б.

*Урманче Ф.И.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: II т. (Д – С). Казан: Мәгариф, 2009. 343 б.

*Урманчеев Ф.И.* Развитие татарского фольклора в контексте «Запад – Восток // Очерки по истории татарской культуры (в контексте «Запад-Восток») / под. ред. М.З. Закиева, Ф.И. Урманчеева, А. И. Садековой. Казань: Фикер, 2001. С. 300–348.

*Фазлетдинов И.К.* Стәрлебаш районы татарлары риваятьләренең тарихи һәм мифологик нигезләре // Милли-мәдәни мирасыбыз: Башкортстан татарлары. Стәрлебаш. 1 нче кисәк / төзүче Н.Ш. Насыйбуллина; фәнни мөхәррир И.И. Ямалтдинов. 2 нче басма. Казан: ТӘһСИ, 2021. Б. 406–435.

*Мәкалә «Татар халкының милли үзтәңгәллеген саклау (2020 – 2024 еллар)» Татарстан Республикасы дәүләт программасының 3.19 номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*

***Фазлетдинов Илдус Камил улы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент;*
*Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе*
*һәм мәдәнияте кафедрасы доценты (Уфа);*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать*
*институтының халык иҗаты бүлеге фәнни хезмәткәре*